ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
V чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
V созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** 15.12.2025 ел

**РЕШЕНИЕ** №03-04

**«Актаныш муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-03 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015, 30.04.2024 № 290, 24.06.2024 № 451, 25.09.2024 № 829, 14.04.2025 № 228 кертелгән үзгәрешләр белән), Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-03 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1 пунктта** «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга.

**күрсәтелгән карарга 3 нче кушымтаны** яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы Рәисе

Л.Р.Зарипов

3 нче кушымта
Актаныш муниципаль районы
Советы карарына
10.02.2023ел, №27-03 (Актаныш
муниципаль районы Советының
15.12.2025 ел №03-04 карары
редакциясендә)

**Актаныш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы аудиторы рәисе, рәис урынбасарының айлык акчалата бүләкләү күләме**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) 8 төркем |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Депутатлар | 21 977 |
| Җирле үзидарәнең сайланган органнары әгъзалары | 18 674 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 40 334 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 36 225 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 30 809 |